ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.04.2024 Олы Кайбыч ав. № 151

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 апрелендәге 190 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 апрелендәге 190 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренә һәм белгечләренә (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) түләү оештыру һәм шартлары турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында (07.02.2022 №57, 12.01.2024 №8 үзгәрешләр белән) нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 31 700 |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 29 500 |
| Бүлек башлыгы | 25 700 |
| Әйдәп баручы хисапчы | 23 300 |
| Хисапчы | 22 000 |

Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия штат расписаниесенә җитәкче урынбасары вазыйфасын кертү шарты булып, структурада штат саны кимендә 5 берәмлек булган кимендә 3 бүлек булу тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләрендә штат саны кимендә 5 берәмлек булырга тиеш.».

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Н.Макаров